МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

23.12.2016 г. Казань № 2737

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында кушымтада бирелгән нигезләмәне расларга (алга таба – Нигезләмә)
2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар үткәрү турында» 22.07.2013 № 1330, «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 22.07.2013 № 1330 боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 28.05.2014 ел, № 1011 боерыкларын үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр А.Ю.Вафин

Р.В. Зарипова,
(843) 231-79-15

ТР Сәламәтлек саклау
министрлыгының
26.12.2016 № 2737
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында

НИГЕЗЛӘМӘ

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә белән Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча конкурс уздыру буенча конкурс комиссиясе (алга таба – конкурс комиссиясе) составы, аның эшләү вакыты һәм тәртибе, шулай ук Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру методикасы билгеләнә.

1.2. Нигезләмә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибен һәм шартларын билгели. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә Конкурс (алга таба – конкурс) Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә тигез дәрәҗәдә үтеп керә алуы буенча конституциячел хокукларын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфаи үсеш хокукын тәэмин итә.

1.3. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында конкурс «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон № 79-ФЗ) 22 статьясы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы (алга таба – Указ № 112), «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә уздырыла.

Конкурс ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә дәгъва белдерүчеләрнең профессиональ дәрәҗәсен, аларның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүгә билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләүдән гыйбарәт.

1.4. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс Федеральным законом № 79-ФЗ нигезендә конкурс нигезендә биләнергә мөмкин булган дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы булганда ТР сәламәтлек саклау

министры карары белән игълан ителә.

1.5. Конкурсны үткәрү турындагы карар Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры тарафыннан структур бүлекчә җитәкчесе әзерләгән язма дәлилләнгән гариза (әлеге Нигезләмәгә Кушымта № 1) нигезендә кабул ителә. Конкурс игълан итү турындагы тәкъдим белән беррәттән гаризада Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасының (алга таба – граждан хезмәте вазыйфасы) атамасы һәм вазыйфаи вазыйфаларның спецификасын исәпкә алып, бу вазыйфаны биләүгә дәгъвачыга карата куелган таләпләр күрсәтелгән тиеш.

1.6. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

а) «җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләрендәге Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфасы вәкаләтләрен билгеле бер вакытка биләп тору өчен билгеләгәндә;

б) вакытлы хезмәт контракты төзегәндә;

в) № 79-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган очракларда Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрен Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләгәндә;

г) граждан хезмәтендә кадрлар резервына кертелгән граждан хезмәткәрен (гражданинны) граждан хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә;

д) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгели һәм азат итә торган «җитәкчеләр» категориясе граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

1.7. Конкурс түбәндәге очракларда үткәрелмәскә мөмкин:

а) граждан хезмәтенең алар буенча вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы нигезендә раслана торган вазыйфалар исемлегендәге аерым вазыйфаларына билгеләгәндә;

б) эшкә алучы вәкиле карары буенча, граждан хезмәтенең кече вазыйфалар төркеменә карый торган граждан хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә.

1.8. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

Россия Федерациясе гражданнарының аларның сәләтләре һәм һөнәри әзерлекләре нигезендә дәүләт граждан хезмәтеннән бертигез файдалану хокукын, шулай ук дәүләт граждан хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфаи үсешкә хокукларын тәэмин итү;

граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә аеруча туры килә торган, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән барлык кандидатлар арасыннан сайлап алу;

ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар резервын формалаштыру.

1.9. Конкурслар үткәргәндә хәл ителә торган мәсьәләләр:

барлык кандидатлар өчен дә алар тарафыннан конкурс биремнәре һәм процедуралары үтәлгәндә тигез шартларны тәэмин итү;

кандидатларны объектив һөнәри әһәмияткә ия критерийлар нигезендә бәяләү;

конкурста катнашучылар арасыннан, конкурс процедуралары барышында алынган объектив һәм нигезле күрсәткечләрне чагыштыру юлы белән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфалары таләпләренә туры килә торган затларны ачыклау.

## 2. Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм эш тәртибе

2.1. Конкурсны үткәрү өчен ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры боерыгы белән даими нигездә эшләүче конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясе составы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы белән раслана. Комиссия составына кертелгән вазыйфаи затларның персональ составын үзгәрткәндә, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы белән тиешле үзгәрешләр кертелә.

2.2. Конкурс комиссиясе рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

2.2.1. ТР Сәламәтлек саклау Министрлыгында «җитәкчеләр» категориясе граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын билгеләнмәгән вакытка вәкаләтләрен биләп торуга конкурс комиссиясен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры җитәкли.

2.2.2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры боерыгы белән граждан хезмәтенең башка вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурслар үткәрү өчен төрле категория һәм граждан хезмәте вазыйфаларының төркемнәре өчен берничә конкурс комиссиясе төзелергә мөмкин.

2.3. Комиссия рәисе конкурс комиссиясе эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, утырыш үткәрү датасын билгели һәм аның көн тәртибен раслый, комиссия утырышларында рәислек итә һәм тиешле документларга кул куя. Комиссия рәисе булмау сәбәпле, аның хокукларын һәм вазыйфаларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан конкурс процедураларын әзерләү һәм үткәрү буенча эшче төркем составы раслана.

Конкурс комиссиясе сәркатибе комиссия эшен (гаризаларны теркәү, кабул итү, эшләрне формалаштыру, конкурс комиссиясе карарларын рәсмиләштерү) тәэмин итә.

2.4. Конкурс комиссиясе составына Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры, аның урынбасарлары һәм (яки) аларга вәкаләтле граждан хезмәткәрләре (шул исәптән граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелә торган ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар бүлегенән, юридик бүлегенән һәм структур бүлекчәсенән), Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, шулай ук министрның запросы буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан чакыртыла торган граждан хезмәте мәсьәләләре буенча бәйсез экспертлар – фәнни, мәгариф һәм башка оешмаларның вәкилләре керә экспертларның шәхси мәгълүматларын күрсәтмичә чакырыла.

ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс комиссиясе составына ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет вәкиле керә.

Вәкилләрнең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми саны конкурс комиссиясендәге барлык әгъзалар санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.5. Вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс уздырылганда, конкурс комиссиясе составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турында законнары нигезләмәләрен исәпкә алып төзелә.

2.6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге калмаслык итеп төзелә.

2.7. Конкурс комиссиясе утырышы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр барлык әгъзаларының кимендә өчтән ике өлеше катнашса, ул тулы хокуклы дип санала. Конкурс утырышын бары тик комиссиянең ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары катнашында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.8. Конкурс комиссиясе түбәндәге карарларны кабул итә:

конкурс үткәрү шартларын регламентлаучы документларны, аны үткәрү өчен кирәкле методик һәм башка материалларны раслый;

конкурс үткәрү план-графигын раслый;

конкурска нәтиҗәләр ясау турында;

конкурс процедураларын үткәрү нәтиҗәләре буенча төзелгән рейтингта беренче урынны алган кандидатлар конкурсында җиңүчеләр дип тану турында;

Татарстан Республикасы граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләү өчен ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар резервына тәкъдим ителгән кандидатлар исемлеген формалаштыру турында.

2.9. Конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән утырышта катнашучы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда конкурс комиссиясе рәисе тавышы хәлиткеч булып тора. Конкурс комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасы, кабул ителгән карар белән килешмичә, комиссия утырышы беркетмәсендә теркәлә һәм конкурс комиссиясенең әлеге әгъзасы имзасы белән беркетелә торган аерым фикер белдерә ала.

2.10. Конкурс нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары кандидатның үзе булмаганда кабул ителә һәм аны вакантлы граждан хезмәте вазыйфасына билгеләү яисә бу вазыйфага билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

Конкурс комиссиясе шулай ук тәкъдим итү характерындагы, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар резервына граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңүче булмаган, әмма һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәя алган кандидатны кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Күрсәтелгән кандидат ризалыгы белән ул ТР Сәламәтлек саклау

министрлыгының кадрлар резервына кертелергә мөмкин.

2.11. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кабул ителә торган карарлар (комиссия тавыш бирү нәтиҗәләре) конкурс комиссиясе беркетмәсе (әлеге Нигезләмәгә кушымта № 2) белән рәсмиләштерелә, беркетмәгә утырышта катнашкан комиссия рәисе, рәис урынбасары, сәркатип һәм комиссия әгъзалары кул куя.

2.12. Конкурс процедурасын эшләү һәм әзерләү буенча эш документлары, конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләре эчтәлеге, конкурс тәмамланганчы конкурс биремнәре исемлеге һәм темалары хезмәтэи файдаланудагы мәгълүмат булып тора.

2.13. Конкурсны оештыруны һәм үткәрүне, конкурс комиссиясе эшен ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар бүлеге гамәлгә ашыра.

## 3. Конкурста катнашучылар

3.1. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларга таләпләргә туры килә торган һәм әлеге Нигезләмәнең 3.2 пунктында каралган срокта барлык кирәкле документларны тапшырган гражданнар (алга таба – кандидатлар) конкурста катнашуга кертелә.

ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында вакантлы вазыйфаны биләүгә кандидатларга таләпләр (әлеге Нигезләмәгә Кушымта № 3) һәм ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатлар тарафыннан бирелә торган документлар һәм материаллар исемлеге (әлеге Нигезләмәгә Кушымта № 4) Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән.

3.2. Конкурста катнашу өчен документлар ТР Сәламәтлек саклау министрлыгына кандидатлар тарафыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми порталында (алга таба – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының рәсми сайты) конкурс үткәрү турында мәгълүмати хәбәр урнаштырылган көннән 21 көн эчендә бирелә. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында вакантлы вазыйфаны биләүгә кандидатлар тарафыннан бирелә торган документлар һәм материаллар исемлеге Кушымта № 4тә күрсәтелгән.

3.3. Җитди сәбәпләрсез документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданинга аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

3.4. Конкурста катнашырга теләк белдергән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының граждан хезмәткәре Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры исеменә гариза бирә.

3.5. Башка дәүләт органында вазыйфа биләүче, конкурста катнашу теләген белдергән граждан хезмәткәре ТР Сәламәтлеек саклау министрлыгына министр исеменә шәхси гариза һәм үзе тутырган, имзалаган һәм үзе граждан хезмәтен били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы күрсәтмәсе белән раслаган формадагы анкетаны, фотосын (4х6, почмаксыз) теркәп, тапшыра.

3.6. Гражданинның (граждан хезмәткәренең) ризалыгы белән аңа дәүләт серен яки законда саклана торган башка сердән торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасы рәсмиләштерелә, әгәр дә гражданин (граждан хезмәткәре) тарафыннан биләү өчен дәгъва белдерелгән граждан хезмәте вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларны үтәү мондый белешмәләрдән файдалануга бәйле булса.

Граждан тарафыннан Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры исеменә бирелгән белешмәләрнең дөреслеге тикшерелергә тиеш.

Граждан хезмәткәрләренә бирелгән белешмәләрнең дөреслеген тикшерү аның ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында граждан хезмәте вазыйфаларының югары төркеменә караган граждан хезмәте вакант вазыйфасын биләп торуга конкурста катнашкан очракта гына гамәлгә ашырыла.

3.7. Гражданин (граждан хезмәткәре) граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына (кадрлар резервындагы граждан хезмәте вазыйфасына) карата квалификация таләпләренә туры килмәве, шулай ук Федераль законда билгеләнгән чикләүләренә бәйле рәвештә конкурста катнашуга кертелми.

## 4. Конкурсны уздыру методикасы

4.1. Конкурсны үткәргәндә кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларына нигезләнгән Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган конкурс биремнәре һәм процедуралар кулланыла.

4.2. Кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерийлары ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының граждан хезмәте вазыйфаларына куела торган квалификация таләпләре нигезендә эшләнгән.

Конкурста катнашучыларны бәяләү критерийларының якынча исемлеге һәм кыскача тасвирламасы әлеге Нигезләмәнең Кушымта № 5тә китерелгән.

Конкурс үткәрелә торган вазыйфалар төркеменә һәм категориясенә карап, конкурста катнашучыларны бәяләү критерийлары үзгәрергә мөмкин.

4.3. Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу алар тарафыннан конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын узу нәтиҗәләре нигезендә башкарыла.

Нәтиҗәләр кандидатларның баллар буенча (рейтинг) исемлеге рәвешендә бирелә.

4.4. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.4.1. Беренче этапта ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының рәсми сайтында һәм дәүләт хезмәте һәм мәгълүмати технологияләр өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында – Интернет телекоммуникацион челтәрендә конкурста катнашу өчен документлар кабул итү турында белдерү, шулай ук конкурс турында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла: граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы атамасы, бу вазифаны биләүгә дәгъвачыга куела торган таләпләр, граждан хезмәтен узу шартлары, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә кандидатлар бирә торган документлар һәм материаллар исемлеге нигезендә тапшырылырга тиешле документларны кабул итү урыны һәм вакыты,

документларны кабул итү срогы, конкурс уздыруның күздә тотылган датасы, аны уздыру урыны һәм тәртибе, башка мәгълүмати материаллар.

Конкурсның беренче этабы ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтларында яисә вакытлы матбугатта конкурс үткәрү турында мәгълүмати хәбәр урнаштырудан башлана һәм 21 көннән дә соңга калмыйча тәмамлана.

4.4.2. Граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъвачылар тарафыннан бирелгән документларны тикшергәннән соң, кадрлар бүлеге Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрына гражданнар (граждан хезмәткәрләре) конкурсында катнашуга рөхсәт яисә аларга конкурста катнашуга мотивлаштырылган рәвештә баш тарту турында карар кабул итү өчен тәкъдим кертә.

Дәгъвачыларның тикшерелгән документлары һәм кадрлар бүлегенең тәкъдиме конкурсның икенче этабын үткәрү турында карар кабул итү өчен Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрына тапшырыла.

4.4.3. Тикшерү барышында гражданинның федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә граждан хезмәтенә керүенә комачаулаучы шартлар ачыкланган очракта, ул кадрлар бүлеге тарафыннан конкурста ккатнаштырудан кире кагуның сәбәпләре турында министр тарафыннан язмача рәвештә хәбәр ителә (әлеге Нигезләмәгә Кушымта № 6).

4.4.4. Конкурста катнашуга кертелмәгән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында вакантлы вазыйфаны биләүгә дәгъва белдергән зат бу карарга Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

4.4.5. Конкурсның беренче этабын тәмамлау шарты булып ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында билгеләнгән таләпләргә туры килә торган бер вакантлы граждан хезмәте вазыйфасына кимендә ике кандидатның булуы тора, бу исә кандидатларны киләчәктә сайлап алу мөмкинлеген тәэмин итә.

Кадрлар бүлеге конкурсның икенче этабы башланганчы 15 көннән дә соңга калмыйча, конкурста катнашуга кертелгән гражданнарга (граждан хезмәткәрләренә) аны үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында хәбәр җибәрә.

Кандидатлар булмаганда яки вазыйфага квалификация таләпләренә туры килгән бер генә кандидат булса, конкурс узмаган дип таныла. Бу очракта бердәнбер кандидатка, конкурс комиссиясе карары буенча, кандидатларның таләп ителгән саны булмау сәбәпле, конкурс үткәрелмәгән дип хәбәр ителә.

4.4.6. Конкурсның икенче этабында түбәндәгеләр башкарыла:

а) кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын конкурс комиссиясе тарафыннан бәяләү;

б) ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста җиңүчене билгеләү турында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министры карары кабул ителә.

4.4.7. Конкурс уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларны алар тарафыннан тапшырылган белеме, граждан яисә башка төрле дәүләт хезмәтен узуы, башка төрле хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруы турындагы документлар

нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларын, шул исәптән ТР Сәламәтлек саклау министрлыгына кандидатлар дәгъва итә торган граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча вазыйфаи бурычларын үтәү белән бәйлетест уздыруны, шәхси әңгәмә уздыруны кулланып, конкурс процедуралары нәтиҗәләре нигезендә бәяли.

4.4.8. ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында конкрет вакантлы граждан хезмәте вазыйфасына кандидатларны тестлау Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен, Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының 2016 елның 11 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнарны тестлау методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.4.9. Тест узган кандидатлар белән шәхси әңгәмә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан үткәрелә.

Шәхси әңгәмә барышында конкурс комиссиясе кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын, граждан хезмәте вазыйфаларына һәм бу вазифа буенча вазыйфаи регламентның башка нигезләмәләреннән чыгып бәяли, шулай ук әлеге Нигезләмә һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка нигезләмәләрдән чыгып, конкурс комиссиясе тарафыннан бирелә торган сорауларга кандидатларның телдән җавап бирүеннән гыйбарәт, аның барышында конкурс комиссиясе кандидатларның профессиональ һәм шәхси сыйфатларын бәяли.

4.5. Конкурсның икенче этабы нәтиҗәсе һәм конкурсның йомгаклау нәтиҗәсе булып конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелгән конкурс комиссиясе карары тора.

4.6. Кандидатлар алган тавышлар саны, кандидат дәгъва итүче структур бүлекчә җитәкчесе фикере (ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы җитәкчелеге) конкурска йомгак ясау һәм ТР Сәламәтлек саклау министрлыгында вакантлы вазыйфаны биләүгә кандидат турында карар кабул итү өчен нигез булып тора.

Конкурста иң күп тавыш җыйган кандидат җиңүче дип таныла.

Конкурста ике яки аннан да күбрәк катнашучы тигез күләмдә балл җыйган очракта, конкурс комиссиясе рәисе фикере хәлиткеч булып тора.

4.7. Конкурсны үткәрү нәтиҗәсендә граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы буенча барлык кирәкле таләпләргә җавап бирүче кандидатлар ачыкланмаса, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынаулары үткәрү турында карар кабул итәргә яисә яңа конкурс үткәрү турында тәкъдим кертергә хокуклы.

4.8. Дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга конкурс нәтиҗәләре буенча ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына конкурста җиңүчене билгеләү турында боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә.

Конкурс комиссиясе тарафыннан ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар резервына конкурс җиңүчесе булмаган кандидатны кертү турында карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән затның ризалыгы белән, граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасы булган шул ук төркем граждан хезмәте вазыйфаларын биләү

өчен, аны ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының кадрлар резервына кертү турында ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы боерыгы чыгарыла.

Конкурста җиңүчене вазыйфага билгеләүгә тәкъдим иткәндә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрына конкурс комиссиясе карары һәм мондый карар кабул итү өчен нигез булган материаллар мәҗбүри рәвештә тапшырыла.

4.9. Конкурста катнашкан кандидатларга кадрлар бүлеге тарафыннан конкурс нәтиҗәләре турында язма рәвештә конкурс тәмамланганнан соң җиде көн эчендә хәбәр ителә.

Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүмат шулай ук Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтларында урнаштырыла.

4.10 Конкурста катнашуга кертелмәгән граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә дәгъва итүчеләрнең һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары аларга конкурс тәмамланганнан соң өч ел эчендә язма гариза буенча кире кайтарылырга мөмкин. Әлеге вакыт чыкканчы документлар кадрлар бүлегендә саклана, шуннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

4.11. Конкурста катнашу (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урыны наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һ. б.) белән бәйле чыгымнар кандидатлар тарафыннан үз акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

4.12. Дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләп торуга кандидат конкурс комиссиясе карарына Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять бирергә хокуклы.

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгында Татарстан
Республикасы дәүләт граждан
хезмәтенең вакантлы вазыйфасын
биләүгә конкурс үткәрү турында
Нигезләмәгә Кушымта № 1

___________________________

Татарстан Республикасы
сәламәтлек саклау министрына

Гариза

Сездән дәүләт граждан хезмәтенең түбәндәге вакантлы вазыйфасын биләү буенча конкурс игълан итүегезне сорыйм________________________________

(вазыйфа, бүлек аталышы)

Күрсәтелгән вазыйфаны биләү өчен дәгъва кылучыга карата түбәндәге таләпләр белдерелә:

_______________________________________________

_______________________________________________

Кушымта: Вазыйфаи регламентның күчермәсе.

_______________ _____________ ______________________

(биләнә торган вазыйфа) (имза) (фамилия һәм инициаллар)

дата

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ

Татарстан Республикасы

сәламәтлек саклау министры урынбасары

________ ___________________________

(имза) (фамилия һәм инициаллар)

«___» _____________ _______ 20 ел

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт
граждан хезмәтенең вакантлы
вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү
турында Нигезләмәгә Кушымта № 2

Конкурс комиссиясе беркетмәсе №____

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының конкурс комиссиясе утырышында биләнәчәк вакантлы вазыйфага карата конкурста сайлап алу буенча тавыш бирелде ________________________________________________

(биләнә торган вакантлы вазыйфа аталышы)

________________________________________________________________________

(структур бүлекчә аталышы)

Утырышта ______конкурс комиссиясе әгъзасының _______ катнашты.
Тавыш бирү нәтиҗәләре:

1. _______________________________ ________ «хуплы», ________ «каршы»
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
2. _______________________________ __________«хуплы »,________ «каршы»
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)
3. _______________________________ ________ «хуплы »,_______«каршы»
(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Тавыш бирү нәтиҗәсендә

________________________________________________________________________

(кандидатның фамилиясе, исеме, атасының исеме)

конкурс комиссиясе әгъзаларыннан иң күп санлы тавыш алды, ул тавыш бирүдә катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары исәбенең ____процентын тәшкил итә.

Конкурс комиссиясе рәисе ________________________
Конкурс комиссиясе рәисе урынбасары ________________________
Конкурс комиссиясе сәркатибе ________________________
Конкурс комиссиясе әгъзалары: ________________________

Конкурс үткәрү датасы «____» ____________ 20____ ел

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгында Татарстан
Республикасы дәүләт граждан
хезмәтенең вакантлы вазыйфасын
биләүгә конкурс үткәрү турында
Нигезләмәгә Кушымта № 3

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә кандидатларга таләпләр

## 1.Гомуми таләпләр

1.1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең (алга таба – граждан хезмәте) вакант вазыйфасын биләп торуга конкурста катнашу хокукына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган, 18 яшькә җиткән, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләргә җавап бируч кирәкле таләпләргә җавап бирүче гражданнар ия.

Граждан хезмәткәре конкурс уздыру вакытына нинди вазыйфа биләвенә карамастан, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакант вазыйфасын биләп торуга конкурста гомуми нигезләрдә катнашырга хокуклы.

1.2. Гражданинның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасына квалификация таләпләренә туры килмәве сәбәпле, шулай ук дәүләт граждан хезмәтенә керү һәм аны узу өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашуга кертелми.

## 2. Квалификация таләпләре

2.1. Граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган, һөнәри белем дәрәҗәсенә, граждан хезмәте буенча яисә белгечлек буенча эш стажына, әзерлек юнәлешенә, белемнәргә һәм күнекмәләргә карата, шулай ук министрның тиешле карары булган очракта, белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә карата квалификация таләпләренә җавап бирү таләп ителә.

2.2. Граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләре граждан хезмәте вазыйфаларының категорияләре һәм төркемнәре, өлкә һәм граждан хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге төре нигезендә билгеләнә.

2.3. Һөнәри белем дәрәҗәсенә квалификация таләпләре:

граждан хезмәтенең иң югары һәм төп вазыйфалар төркемнәрендә «җитәкчеләр», «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)», «белгечләр» категориясендәге граждан

хезмәте вазыйфаларын биләү өчен белгеч, магистратура дәрәҗәсеннән түбән булмаган югары белемгә ия булу мәҗбүри;

гражданхезмәтенең иң югары вазыйфалар төркемендә «җитәкчеләр», «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләрендәге, граждан хезмәтенең әйдәүче һәм өлкән төркемнәренең «белгечләр» категориясендәге, шулай ук граждан хезмәтенең төп һәм әйдәүче төркемнәренең «тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен югары белемгә ия булу мәҗбүри;

граждан хезмәтенең өлкән һәм кече төркемнәрендә «тәэмин итүче белгечләр» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен һөнәри белемгә ия булу мәҗбүри.

2.4. Граждан хезмәте стажына яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата граждан хезмәткәрләренә граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен кирәкле булган квалификация таләпләре:

граждан хезмәтенең иң өлкән вазыйфалары төркеменең «җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләрендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – кимендә өч еллык граждан хезмәте стажы яисә белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча кимендә җиде еллык эш стажы;

граждан хезмәтенең иң югары вазыйфалары төркеменең «белгечләр» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – кимендә өч еллык граждан хезмәте стажы яисә белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча кимендә биш еллык эш стажы;

граждан хезмәтенең баш вазыйфалары төркеменең барлык категорияләрендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – кимендә ике еллык граждан хезмәте стажы яисә белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча кимендә өч еллык эш стажы;

граждан хезмәтенең әйдәүче вазыйфалары төркеменең барлык категорияләрендәге граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен – кимендә бер еллык граждан хезмәте стажы яисә белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча кимендә ике еллык эш стажы.

Граждан хезмәтенең өлкән һәм кече вазыйфалар төркемнәренең граждан хезмәте вазыйфаларын биләү өчен граждан хезмәте стажына яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре билгеләнми.

Граждан хезмәте стажын билгеләгәндә шулай ук федераль дәүләт граждан хезмәтенең тиешле вазыйфалар төркемнәрендәге вазыйфаларда, хәрби вазыйфаларда һәм бүтән федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларында, дәүләт вазыйфаларында, муниципаль вазыйфаларда, тиешле вазыйфа төркемнәренең муниципаль хезмәт вазыйфаларында, бүтән вазыйфаларда эшләү стажы федераль законнарга туры китереп исәпкә алына.

2.5. Граждан хезмәтенең баш һәм әйдәүче вазыйфа төркемнәренең «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категориясендәге һәм граждан хезмәтенең баш һәм әйдәүче төркемнәренең «белгечләр» категориясендәге граждан хезмәте вазыйфаларын эшчәнлек юнәлешенә туры килә торган фәнни дәрәҗәгә ия булган затлар биләгәндә, шушы Таләпләрнең 2.4 пунктында билгеләнгән граждан хезмәтенә яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына карата квалификация таләпләре дәүләт органы җитәкчесенең карары буенча исәпкә алынмаска мөмкин.

2.6. Бик яхшы билгеләренә белгеч яки магистр дипломына ия булган затлар өчен диплом тапшырылган көннән башлап өч ел дәвамында граждан хезмәтенең әйдәүче вазыйфаларын биләү өчен граждан хезмәте стажына яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча квалификация таләпләре билгеләнә – кимендә бер еллык граждан хезмәте яки белгечлеге, әзерлек юнәлеше буенча эш стажы.
2.7. Вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган белемнәргә һәм осталыкларга карата квалификация таләпләре граждан хезмәткәренең һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә һәм төренә карап, аның вазыйфаи регламентында билгеләнә. Граждан хезмәткәренең вазыйфаи регламентында шулай ук белгечлегенә, әзерлек юнәлешенә карата граждан хезмәте вазыйфасын биләү өчен зарури булган квалификация таләпләре дә каралырга мөмкин.

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгында Татарстан
Республикасы дәүләт граждан
хезмәтенең вакантлы вазыйфасын
биләүгә конкурс үткәрү турында
Нигезләмәгә Кушымта № 4

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү (кадрлар резервына керү) буенча кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлеге

1. Конкурста катнашу теләген белдергән Россия Федерациясе гражданины Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәгеләрне тапшыра:

а) шәхси гариза (әлеге исемлеккә кушымта итеп бирелә);

б) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы карары белән раслаган рәвештәге, тутырылган һәм имзаланган анкета, ике 4х6 фотосы белән;

в) Паспорт яки аны алмаштыра торган документ күчермәсе (тиешле документ конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

г) Кирәкле һөнәри белемне, квалификацияне һәм эш стажын раслый торган документлар:

хезмәт кенәгәсенең (эшкә (хезмәт итүгә) бәйле эшчәнлек беренче мәртәбә гамәлгә ашырыла торган очраклардан кала) нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе яки гражданинның эшкә бәйле (хезмәт итү) эшчәнлеген раслый торган бүтән документлар;

белем алу турында һәм квалификация турындагы документларның күчермәләре, шулай ук, ихтыяры буенча, өстәмә һөнәри белем алу нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яки бирелүен раслый торган документларның, гыйльми дәрәҗә, гыйльми исем бирелүе турындагы документларның нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләре;

д) Россия Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2009 елның 14 декабрендәге 984н номерлы боерыгы белән расланган формада гражданинда граждан хезмәтенә керү яисә аны узу өчен каршылык тудыручы авыру юклыгы турында документ;

е) «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль законда, бүтән федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгына Татарстан
Республикасы дәүләт граждан
хезмәтенең вакантлы
вазыйфаларын биләүгә
кандидатлар тарафыннан бирелә
торган документлар һәм
материаллар исемлегенә Кушымта

Татарстан Республикасы
сәламәтлек саклау министрына

___________________________

(фамилия, инициаллар)

кемнән
(фамилия, исем, атасының исеме)

Адрес
Тел.

Гариза

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурста катнашырга кертүегезне сорыйм: ___________________________________

(вазыйфа , бүлек, Идарә аталышы)

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге 112 номерлы Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү турында Нигезләмә белән, шул исәптән күрсәтелгән вазыйфага куела торган квалификация таләпләре белән дә, таныштырылдым.

Дәүләт серен яки законда саклана торган башка сердән торган белешмәләрдән файдалануга рөхсәт бирү процедурасын үткәрү белән килешәм.

Конкурсны үткәрү датасы һәм урыны турында хәбәрне email яки күрсәтелгән мобиль телефон номерына смс аша хәбәр алуга риза.

Гаризага <*> кушып бирәм: (кушып бирелә торган документларны санап үтәргә).

"__" _______ 20 __ел ____________________

(имза)

<*> Гариза кулдан языла.

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгында Татарстан
Республикасы дәүләт граждан
хезмәтенең вакантлы вазыйфасын
биләүгә конкурс үткәрү турында
Нигезләмәгә Кушымта № 5

## Конкурста катнашучыларны бәяләү критерийлары

### 1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте культурасына җавап бирү

1.1. Һөнәри максатчанлыгы:

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтендә һөнәрдә шәхси потенциал үстерүгә омтылу, дәүләт идарәсе өлкәсендә хезмәттә үсүне күздә тоту.

1.2. Гражданлык позициясе:

Эшчәнлектә җәмгыятькә һәм дәүләткә хезмәт итү, законнарны, хезмәт этикасы кагыйдәләрен саклау принципларын үтәү.

1.3. Һөнәри позициядәге активлыгы

Куелган мәсьәләләрне хәл иткәндә инициатива күрсәтергә омтылу; мөмкин булган иң яхшы нәтиҗәгә ирешү өчен хәлдән килгәнчә тырышлык күрсәтергә әзер булу, физик һәм эмоциональ басым шартларында нәтиҗәле эш-гамәл кылуга (стрессларга каршы торуга) сәләтле булу.

1.4. Үз-үзен үстерүгә әзер булуы:

Үз белемнәреңне, осталыкларыңны һәм күнекмәләреңне даими камилләштерергә, карашларыңны киңәйтергә, катнаш һөнәр өлкәләрендә белемнәр һәм тәҗрибә алырга омтылу.

### 2. Дәүләт хезмәткәренең һөнәри компетентлыгы

2.1. Белем дәрәҗәсе:

Төп һәм өстәмә һөнәри белем дәрәҗәсе, юнәлеше һәм сыйфаты

2.2. Һөнәри тәҗрибәсе:

Тиешле һөнәр өлкәсендәге эшчәнлек итү озынлыгы һәм үзенчәлекләре; һөнәри эшчәнлектә билгеле бер нәтиҗәләргә ирешү; карьера үзенчәлекләре.

2.3. Махсус һөнәри белемнәре, осталыклары һәм күнекмәләре:

Тиешле өлкәдә вазыйфаи бурычларын нәтиҗәле башкару мөмкинлеген бирә торган һөнәри белемнәр дәрәҗәсе; һөнәри эшчәнлекне регламентлый торган Россия Федерациясе законнарын белү; заманча профессиональ технологияләр белән эш итә белү.

2.4. Гомуми инструменталь күнекмәләре:

Һөнәри эшчәнлекнең гомуми нәтиҗәлелеген арттыра торган күнекмәләргә ия булу дәрәҗәсе (компьютер белү, гомуми грамоталылык, чит телләр белү һ. б.).

## 3. Граждан хезмәтенең шәхси-эшлекле сыйфатлары

3.1. Аналитикага бәйле сәләтләре:

Мәгълүматларны анализлауны һәм структуралаштыруны таләп итә торган катлаулы мәсьәләләрне хәл итү мөмкинлеген бирә торган системалы һәм сыгылмалы фикерләү дәрәҗәсе; яңа, стандарт булмаган чишелешләр таба белү сәләте.

3.2. Нәтиҗәле коммуникацияләү күнекмәләре:

Эшлекле сөйләм этикасын саклау; үз фикереңне дәлилле яклый белүгә һәм оппонентларны ышандыра алуга сәләтле булу; эшлекле сөйләшүләр алып бару күнекмәләренә ия булу.

3.3. Җаваплылыгы:

Карарларны кабул итүдә нигезле һәм мөстәкыйль эш итү; нәтиҗәгә ирешүдә үз өстенә алган йөкләмәләрне үтәргә әзер булу.

3.4. Оештыруга бәйле сәләтләре:

Үз эшчәнлеген һәм үзенә буйсынып эшләүчеләр эшчәнлеген нәтиҗәле планлаштыру, вазыйфаларны, вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны бүлеп бирү хисабына нәтиҗәләргә ирешә белү.

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгында Татарстан
Республикасы дәүләт граждан
хезмәтенең вакантлы вазыйфасын
биләүгә конкурс үткәрү турында
Нигезләмәгә Кушымта №6

Кемгә ______________

Адрес ______________

Хөрмәтле __________________!

Сезгә Сезнең Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгында дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү буенча конкурста катнашуга кертелмәвегез турында хәбәр итәм _______________________________________
(граждан хезмәтенең, бүлекнең аталышы) түбәндегеләргә бәйле рәвештә:

(кирәклесен сайларга)

а) вакантлы граждан хезмәте вазыфасына карата квалификация таләпләренә туры килмәү;

б) граждан хезмәтенә керү һәм аны узу өчен дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләмәләр;

в) документларны үз вакытында тапшырмау (аларны тулы булмаган күләмдә яки игътибарга алырлык сәбәптән башка рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру);

г) тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив хокукый актлары нигезендә гражданинның дәүләт хезмәтенә керүенә комачау итүче шартлар билгеләнү.

Сезгә документлар түбәндәге адреска язмача гариза нигезендә кайтарылырга мөмкин: 420111, Казан шәһәре, Островский ур., 11/6 Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, кадрлар бүлеге, каб. № 104, телефон: (843)231-79-17, (843)231-79-15, факс: (843) 231-79-15.

Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры